КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 апрель г.Казань № 202

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 207 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 13 май, 313 нче, 2021 ел, 2 март, 109 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$1^1$ пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартында:

5 пунктта:

беренче абзацта «ике структур бүлекчә» сүзләреннән соң «, башка структур бүлекчәләр составына керми торган» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «ике структур бүлекчә» сүзләреннән соң «, башка структур бүлекчәләр составына керми торган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «өч структур бүлекчә» сүзләреннән соң «, башка структур бүлекчәләр составына керми торган» сүзләрен өстәргә;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Министр урынбасары буйсынуында департамент яки идарә формасында бер бүлекчә булырга мөмкин. Шул ук вакытта аның вазыйфасы «министр урынбасары - Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты директоры» яисә «министр урынбасары - Татарстан Республикасы министрлыгы идарәсе башлыгы» дип атала.»;

12 пунктта:

өченче абзацта «41 дән алып 100 берәмлеккә кадәр» сүзләрен «40 берәмлектән артык» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктта «(бүлекләр, секторлар)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 ел, 02 март, 109 нчы карарына, 4 пунктта «2021 елның 1 апреленә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 июленә кадәр» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин